**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**28.08.2020 ел** **№169**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 декабрендәге 155 номерлы "Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына бюджеты турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 декабрендәге 155 номерлы "Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына бюджеты турында" (08.04.2020 ел №159, 29.05.2020 ел №161, 29.07.2020 ел №167 үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктында:

а) 1 өлештә "3933,1" санын "5473,9" санына алмаштырырга";

б) 2 өлештә "4183,1" санын "5723,9" санына алмаштырырга";

в) авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 250 мең сум тәшкил итә.

1.2. 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "2020 елга Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары"н әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.3. 2 нче кушымтаның 2 нче таблицасына "Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең 2020 нчы елга фаразланган керем күләме" н әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.4. 5 нче кушымтаның 1 нче таблицасына «2020 нчы елга Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.5. 6 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "2020 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча Зәй муниципаль районы Урсайавыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү"гә үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә редакциядә бәян итәргә:

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Урсай авыл җирлеге Советы рәисе** **Н.А. Гатина**